**Исполнительный комитет Шигалеевского сельского поселения Пестречинского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты**

*422788, РТ, Пестречинский район, с. Старое Шигалеево, ул. Центральная, д. 45*
*Тел./факс: 8(84367) 39-1-24 E-mail Shig.Pes@tatar.ru*

№ 7 «06» июня 2022г.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгының 2022 елның 03 июнендәге 501 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 10 июнендәге 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШИГАЛЕЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * СОВЕТ ШИГАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1633000987